РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

:3950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

:3950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

«03» 04 2019 г. — №305

ТР Ютазы мунииипаль районы Башкарма
комитеты каршындагы район торак-көнкүреш
комиссиясен яңа составта раслау турында

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу һәм торак урыннары бирү тәртибен камилләштерү максатларында, Башкарма комитет карар итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы район торак-көнкүреш комиссиясен яңа составта, Кушымта №1 нигезендә расларга.

2. "Район торак-көнкүреш комиссиясе турында"гы Нигезләмәне Кушымта №2 нигезендә расларга.

3. Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 мартындагы 116 номерлы карары үз көчен югалткан дип исәпләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР ЮМР Башкарма комитеты җитәкчесе — С.П. Самонина

Н.А. Абильтарова

2-76-81

Кушымта №1

Ютазы муниципаль районы Башкарма

комитеты җитәкчесе Карарына

“__” ________ 2019 ел №____

Район торак-көнкүреш комиссиясе составы

Самонина С.П. - Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Шәрипов Р.Ә. - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары;

Абильтарова Н.А. - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге начальнигы, комиссия секретаре.

Комиссия әгъзалары:

Ларин М.В. - юридик бүлек начальнигы;

Саматова А.А. - коррупциягә каршы көрәш буенча район Башлыгы ярдәмчесе;

Нигъмәтуллин Т.И. – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе (килешү буенча);

Захаров А.Н. - инфраструктураны үстерү бүлеге начальнигы (килешү буенча);

Рәшитова З.Ә. – ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Ютазы муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча);

Шуть А.Р. - техник инвентарьлаштыру бюросының 11санлы Ютазы районы төркеме җитәкчесе (килешү буенча);

Кушымта №2

Ютазы муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе

Карарына

“__” __________ 2019 ел №__

**Нигезләмә**

**“Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак-көнкүреш комиссиясе турында”**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Торак-көнкүреш комиссиясе Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан төзелә.

1.2. Комиссия составы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

1.3. Торак-көнкүреш комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы торак закончалыгына, башка норматив һәм хокукый актларга, шулай ук әлеге нигезләмәгә таяна.

## 2. Торак-көнкүреш комиссиясенең төп бурычлары

Торак - көнкүреш комиссиясенең төп бурычлары булып тора:

2.1. Социаль наем килешүләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен гражданнар гаризаларын карау;

2.2. 2007 елның 13 июлендәге “Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында”гы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу турында карар чыгару өчен кирәкле документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

2.3. Гражданнарны социаль наем килешүләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу һәм һәм исәпкә алудан баш тарту турында карарлар әзерләү;

2.4. Исәпкә алу турында гражданнарның гаризаларын теркәү Кенәгәсен, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алынган гражданнарны исәпкә алу Кенәгәсен тутыру һәм алып бару, законнар нигезендә исәпкә алынган гражданнарның исәп эшләрен контрольдә тоту;

## 3. Торак-көнкүреш комиссиясе составы

Торак- көнкүреш комиссиясе составына җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Торак-көнкүреш комиссиясе рәис тарафыннан җитәкчелек ителә. Торак - көнкүреш комиссиясе рәисе булмаган очракта, аның бурычлары комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

Кворум өчен торак- көнкүреш комиссиясе составы әгъзаларның саны так булырга тиеш, әмма 5 (биш) кешедән дә ким булмавы шарт.

## 4. Торак – көнкүреш комиссиясе эшчәнлеген оештыру

4.1. Торак - көнкүреш комиссиясе рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

4.2. Торак - көнкүреш комиссиясе утырышлары расланган план нигезендә үткәрелә, әмма кимендә бер айга бер тапкыр. Утырышлар, иҗтимагый торак комиссиясе әгъзаларының 50 проценттан артыгы катнашса, тулы хокуклы санала.

4.3. Җирле үзидарә органнары яисә юридик зат тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи зат гражданнарны исәпкә алу мәсьәләсен карау өчен кирәкле барлык документларны әзерли.

4.4. Торак - көнкүреш комиссиясе утырышында тикшерелә торган гражданнарны торак урынын булдыру өчен исәпкә алу (баш тарту) мәсьәләләре иҗтимагый торак комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.5. Иҗтимагый торак комиссиясе карары, әгәр аның өчен комиссия әгъзаларының күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Торак-көнкүреш комиссиясе карары тәкъдим итү характерында була.

4.6. Торак - көнкүреш комиссиясе карарын исәпкә алып, Башкарма комитет җитәкчесе белән гражданнарны исәпкә алу (баш тарту) турында Карар, гаиләне исәптән төшерү турында күрсәтмә әзерлиләр.

4.7. Җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи зат, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләр реестрын төзи, аны Башкарма комитет җитәкчесе белән раслый .

4.8. Төрак-көнкүреш комиссиясе хисап эшләрен формалаштыру, алып бару, формалаштыруның дөреслеген контрольдә тоту, закөнчалык нигезендә торак шартларын яхшырту буенча исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлеген саклау эшендә катнаша.

4.9. Торак-көнкүреш комиссиясе ел саен (киләсе елның 1 апреленә кадәр) торак шартларын яхшырту өчен гариза биргән кешеләрне яңадан теркәүдә катнаша.

## 5. Иҗтимагый торак комиссияләре җаваплылыгы

Иҗтимагый торак комиссиясе әгъзалары гамәлдәге закончалык нигезендә торак шартларын яхшырту өчен реестр формалаштыру, исәп эшләрен алып бару һәм гаиләләрнең локаль исемлеген саклау буенча җаваплы.